СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №141 (7440) | 26 ноябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

ДУСЛЫК

**Хөрмәтле укучылар!**

Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.

## Продукция сатуга чыгарылды

Тимер юлчылар эшчеләрне тәэмин итү бүлегенең «Радуга» кибетенә ит комбинатында әзерләнгән беренче партия колбасалар җомга көнне чыгарылды. «Одесская», «Молочная», «Отдельная», «Московская» кебек популяр сортлы продукциянең сыйфаты да, бәяләре дә сатып алучылар күңеленә хуш килерлек иде. Кибет мөдире Л. П.Фролова әйтүенә караганда, яңа продукция бик тиз сатылып беткән һәм-аның сатуга янә кайчан чыгарылачагы белән кызыксынучылар бик күп икән.

Якын арада—яңа төр продукция ит комбинаты директоры Р. С. Чахмахчев әйтүенчә, нефтьчеләр эшчеләрне тәэмин итү бүлеге кибетләренә озатылачак.

## Эшләр кызу бара

99 нчы СПТУ төзелеше --бүген хуҗалыкара төзелеш оешмасы өчен иң мөһим объектларның берсе санала. Ел ахырына кадәр биредәге котельня, гараж, җылылык җайланмалары, 18 фатирлы торак йорт, бер тулай торак файдалануга тапшырылырга тиеш. Шушы көннәрдә 18 квартиралы йорт бүлмәләреннән ачкычлар тапшырылды, йорт яңа хуҗаларының эшлекле, шатлыклы шау-шуына күмелде. Хәзер калган объектларны да өлгертү өчен кызу эш бара. Р. Кузьмина җитәкчелегендәге бизәүчеләр, А. Ильин кул астындагы балта осталары, Ф. Исхаковның ташчылар бригадалары, слесарьлар, сантехниклар объектта эшне тизләтү өчен бар көчләрен куялар. Киләсе елда комплексның уку корпусы, мастерскойлар, тагы бер йорт һәм тулай торакны өлгертү күздә тотыла.

## Аренда звеносында эш гөрли

Аларны берничә ел аренда звеносында янәшә хезмәт берләштерә. Звено җитәкчесе Владимир Петрович Мандрейкин коллективны җитештерүчән хезмәткә туплап, җир белән эшләүдә агротехник таләпләрне һәм срокларны үтәүне, сыйфатлы хезмәт куюны беренче төп таләп итсә, звено членнары, шул исәптән Владимир Валентинович Михеев та шул бурычларны тормышка ашыруда бердәм хезмәт куйдылар. Соңгы елны берләшмә киңәшеп аренда коллективы булып түгел, бары бер звено булып кына эшләде. Әмма элек куелган таләпләр, элек урнаштырылган тәртип, эшкә җаваплы караш үзгәрмәде. «Россия» колхозы кырларында быел үстерелгән мул уңыш шуңа ачык дәлил. Хәзер хуҗалык механизаторлары, шул исәптән Мандрейкин егетләре дә техниканы киләсе ел кыр эшләренә әзерләү буенча киң эш җәелдерделәр. Бүгенге көнгә бидә культиваторлар, бөртек чәчкечләр, таккычлар һәм тигезләгечләр тулысынча сафка бастырылды, калган техниканы да үз срогына сыйфатлы итеп әзерләү—аларның төп максаты.



РӘСЕМДӘ: «Россия» колхозы механизаторлары В. П. Мандрейкин һәм В. В. Михеев.

## Ферма хәбәрләре

### Узган елгы дәрәҗәне узып

Синдряков исемендәге колхоз товарлыклы-сөтчелек фермасында 10 айлык планнарын уңышлы гына үтәп чыктылар. Колхоз буенча һәр сыердан 2765 килограмм сөт савып алдылар. Бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 530 килограммга артык. Ә аерым группаларда бу күрсәткечләр тагы да югарырак. Мәсәлән, Екатерина Захарова белән Зинаида Микушкина группасында 50 баш савым сыерының һәрберсеннән 3024 килограмм сөт савып алдылар. Алар сөт җитештерүгә бирелгән чыгымнарны да бәрәкәтле тотарга тырышалар. Р а ц и о н н а р д а азык мул һәм төрледән. Бу билгеле сөт артуга яхшы яктан тәэсир итә.

**Н. ХРАМОВА.**

### Сыйфатлы продукция алу өчен

Хафизов исемендәге колхозда соңгы елларда товарлыклы-сөтчелек фермасында эш ике сменада оештырылган. Ике группа сыерларын берләштереп бер группага җыйганнар. Аларны ике савучы карый. Минҗиһан Сәйфуллина белән Тәнзилә Җамалова соңгы елларда бер группага хезмәт күрсәтәләр. Алар икәү бергә тату, уртак тел табып, берберсен ихтирам итеп эшлиләр.

Тәнзилә Җамалова фермада 20 елга якын эшли инде, хезмәттә бай тәҗрибәсе булудан тыш, бик күп матур сыйфатларга да ия. Терлекчелеккә ул үзе теләп килде, үзен бу җаваплы эштә күрсәтергә теләге зур иде. Һәм ул аңа иреште дә. Аның маллар белән эш итүдә игътибарлылыгы, йомшак карашы зур роль уйный. Малкайларын ягымлы итеп кушаматлары белән атый, сыйпый, алары да аны аяк тавышыннан таныйлар. Ә кәефсез килеп керсә, алар шунда ук башларын селкеп, канәгатьсезлек белдерәләр. Шуның өчен дә Тәнзилә алар белән гел ягымлы, итәгатьле булырга тырыша. Ул яшьтән үк хезмәтне яратып, күңел шатландырырлык итеп башкарырга күнеккән. Болар барысы да аның хезмәтен билгеләүче төп сыйфатлар булып торалар.

Минҗиһан Сәйфуллина да хезмәттәшенә бик уңай кулдаш булды. Хезмәт күрсәткечләре буенча алар колхозда беренче урында баралар: Минҗиһан Сәйфуллина белән Тәнзилә Җамалова һәр сыердан 3682 килограмм сөт савып алдылар. Елны 4000 леләр сафында тәмамларга тырышалар. Савучылар сыерларны бозаулатуга да әйбәт һәм дөрес әзерлиләр, чөнки киләчәктә алардан тагы да югарырак продукция алырга тырышалар. Мәйсәрә Габбасова белән Затия Ганиева да сынатмыйлар, алар да 1992 нче елның 10 аенда һәр сыердан 3313 әр килограмм сөт савып алдылар.

**Л. ЯРУКОВА.**

### Коллективның эшләре

«Россия» колхозы товарлыклы-сөтчелек фермасы коллективы кышлату чорын уңышлы башлап җибәрде. Савучылар малларны ремонтлаган, төзек биналарга кайтардылар. Хәзер савучылар бер максат—кышлату чорын уңышлы үткәрү һәм шушы чорда да маллардан продукция алуны киметмәү өчен тырышалар. Агымдагы елның 10 аенда алар колхоз буенча һәр сыерга 3175 килограмм сөт саудылар. Хәзергесе көнгә бер сыерга көнлек савым 8 килограмм тәшкил итә, бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 2 килограмм 300 граммга артык. Хуҗалык дәүләткә сөт сатуның еллык планын күптән үтәде инде. План буенча җиткерелгән 7200 центнер урынына ул 8102 центнер сөт сатты.

Ә колхозның алдынгы савучылары Валентина Петровна Наумова үзенә беркетелгән группа малларыннан 619 центнер тулай продукция җитештереп, бер сыердан 3824 килограмм сөт савып алды һәм колхоз буенча беренче урынны яулады. Ольга Михайловна Перелкина да үзенә беркетелгән сыерлардан 575 центнер, бер сыердан 3531 килограмм сөт алып икенче урынга чыкты. Шулай ук Полина Семеновна Корчукова да үзенә беркетелгән сыерлар группасыннан 549 центнер, бер сыердан 3357 килограмм сөт савып алды һәм колхоз буенча өченче урынны яулады. Коллективны шулай бердәм хезмәткә туплауда ферма мөдире Илья Ивановнч Яллинның да өлеше зур. Эштә өзекләр килеп чыкмасын өчен ул бар тырышлыгын куя.

**Н. МИҢҺАҖЕВА.**

## Ишетмәсәң — ишет!

Борис Ельцинның край өлкә һәм автономияле берәмлекләр администрация башлыклары белән очрашуы чит кешеләрне катнаштырмыйча гына үткәрелде. Анда башкарма хакимият органнары җитәкчеләреннән Губернаторлар берлеге оештыру турында килештеләр. Россия халык депутатлары Съездында демократик һәм консерватив көчләргә каршы тору өчен Президент реаль властька ия булган территория җитәкчеләренең булышлыгына исәп тота, күрәсең.

✦

Нәкъ Фигаро кебек: СССРның экс-президенты Михаил Горбачев декабрьдә Чилигә барырга җыена. Анда ул ике көн булачак, лекцияләр укыячак. Ә 19 ноябрьдән 4 декабрьгә кадәр Аргентинада булачак, 9 декабрьдән—Мексикага визит белән китәчәк...

✦

«Безгә халыкларны алдаудан туктарга кирәк», —Казахстан Президенты Н. Назарбаев БДБ кысаларында үткәреләторган очрашуларга әнә шундый бәяне бирде. Минскида булачак чираттагы очрашу, аның фикеренчә, барлык шик-шөбһәләргә нокта куярга тиеш. Безгә сүздә генә түгел, ә эштә бергәләп хәрәкәт итәргә, яисә тыныч кына таралышып, кем ничек булдыра ала, шулай яшәргә кирәк, диде ул.

✦

Новгород өлкәсенең Холм шәһәре урамнарында ашыгыч ярдәм күрсәтүчеләрне, янгын сүндерүчеләрне һәм милиция нарядын чакыру номерларын гына түгел, бәлки барлык башка номерларны да «бушлай җыярга» мөмкин. Телефон-автоматларның халыкка хезмәт күрсәтү чыгымнарын шәһәр Советы үз өстенә алды.

